РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ МОКРОСАВАЛЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МӨКЕРЛЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«21» сентябрь 2016 ел № 19-1

«Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының
Мөкерле авыл җирлеге Җирдән файдалану
һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр
кертү турында»

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Мөкерле авыл җирлеге Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясы 5 пункты, Россия Федерациясе Җир кодексы, Татарстан Республикасы Җир кодексының 34 статьясы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Мөкерле авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы, 2007 елның 21 маендагы 2-23 номерлы Буа муниципаль районы Мөкерле авыл Советының карары белән расланган Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Мөкерле авыл җирлегендә ачык тыңлаулар уздыру турындагы нигезләмә нигезендә Буа муниципаль районы Мөкерле авыл җирлеге Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

I. Буа муниципаль районының Мөкерле авыл җирлегенең 2013нче елның 20 нче февралендәге 1-37 номерлы карары белән расланган Буа муниципаль районының Мөкерле авыл җирлеге Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 30 статьяның 1.2. пунктының 2 абзацын үзгәртергә һәм киләсе редакциядә бәян итәргә:

1.2. Җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан файдалану рөхсәт ителгән чик параметрлары
Кишәрлек зурлыгы:
Җир кишәрлекләренең минималь һәм максималь үлчәмнәре җирлек Советы тарафыннан кабул ителә.
Җир кишәрлекләренең тәкъдим ителә торган күләмнәре:
Кишәрлекнең минималь күләме - 0,04 га
Кишәрлекнең максималь күләме - 0,5 га

II. Буа муниципаль районының Мөкерле авыл советы карары белән расланган Буа муниципаль районының Мөкерле авыл җирлеге Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең 2013елның 20 февралендәге 1-37 номерлы яңа редакциясен хупларга.

III. Әлеге карар «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда интернет мәгълүмат-коммуникация челтәрендә рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

IV. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Буа муниципаль районы Мөкерле
авыл җирлеге башлыгы В.П. Носов